## ВИЧ статусың турындагы мәгълүмат сиңа ничек ярдәм итә ала

1. Әгәр анализ нәтиҗәләре синдә ВИЧ юк дип күрсәтә икән, син үз яшәү рәвешеңнең зарарлану куркынычы белән бәйле булуын беләсең, димәк, аны үзгәртә һәм киләчәктә инфекция йоктыруны булдырмый кала аласың.
2. Әгәр нәтиҗәләр синдә ВИЧ бар дип күрсәтә икән, син тормышыңны куркыныч астына куярлык авыруларны булдырмас өчен шунда ук медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итә аласың. Тикшерену һәм дәвалау никадәр иртәрәк башлана, сәламәтлегеңне саклап калу өчен шансларың шуның кадәр күбрәк диган сүз.
3. Әгәр дә үзеңдә ВИЧ булуын беләсең икән, әйләнә-тирәңдәгеләрне – сексуаль партнерларны һәм наркотик кабул итүчеләрне инфекция йоктырудан саклый аласың.
4. Әгәр дә синдә ВИЧ һәм син әни булырга җыенасың икән, вакытында табибларга мөрәҗәгать иткән һәм СПИД үзәге билгеләгән махсус медицина препаратларын (профилактик АРВТ) регуляр рәвештә кулланган очракта, син вирусны балага йоктыру куркынычын шактый (2% ка кадәр) төшерә аласың.
5. Әгәр дә син үзеңдә ВИЧ булып та, партнерыңда ВИЧ булмавын беләсең икән, сез сексуаль яктан куркыныч булмаган, ягъни, партнерыңа ВИЧ йоктырмый торган, һәм алай гына да түгел, киләчәктә сәламәт балалар алып кайту өчен киртә булмаслык ысулны куллану турында килешә аласыз.
6. Тикшерену нәтиҗәләрен белү сиңа “бәлки миндә ВИЧ һәм мин аны белми йөримдер” дигән куркыныч уйлардан, билгесезлектән котылырга ярдәм итәчәк.
7. Россиядә ВИЧ-инфекцияне заманча дәвалаудан файдаланырга мөмкин һәм ул бушка тәкъдим ителә


СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУНЫҢ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМИЯЛЕ ОЕШМАСЫ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ СПИД һӘМ ЙОГЫШЛЫ АВЫРУЛАР БЕЛӘН КӨРӘШҮ һӘМ ПРОФИЛАКТИКА БУЕНЧА РЕСПУБЛИКА ҮЗӘГЕ»



Ачык Сәламәтлек Институтының материаллары кулланылды


www.infospid.ru



# ВИЧка тикшерену ни өчен әһәмиятле?

## Нәрсә ул ВИЧ, СПИД?

**ВИЧ** -кешеләрдә була торган иммунодефицит вирусы (шуның кыскартылган атамасы).

**В** (вирус) - тере организм күзәнәкләренең эчендә генә үрчи ала торган микроорганизм.

**И** (иммунодефицит) - организмның иммун (саклау) системасының нормаль эшчәнлеге бозылу. Ул организмның кайбер авыруларга каршы тору сәләте кимүгә китерә.

**Ч** (человек – кеше) – бу вирус кешеләргә генә йога.

**СПИД:**

**С** (синдром) – төрле авыруларны һәм халәтләрне бер-берсеннән аерып тора торган билгеләр һәм симптомнар (СПИД белән авыручының күптөрле авырулары һәм шуңа бәйле инфекцияләре булырга мөмкин).

**П** (приобретенный – кабул ителгән, алынган) – ягъни, тумыштан килгән түгел, ә яшәү барышында йоктырылган.

**И** (иммуно-) – ягъни, кешенең төрле авырулар китереп чыгара торган бактерия, вирус һәм гөмбәләрдән саклый торган иммун системасына караган.

**Д** (дефицит) – ягъни, нәрсәнең дә булса җитешмәве.

**ЛЖВ** – ВИЧ белән зарарланган кешеләр «уңай ВИЧлы», «ВИЧ инфекцияле, «ВИЧ белән яшәүчеләр» дип йөртеләләр.

Димәк, ВИЧ – ул кешеләргә йога торган вирус, ә СПИД – уңай ВИЧлы кешедә барлыкка килергә һәм көчәергә мөмкин булган авыру.

## ВИЧ ничек йога?

ВИЧ инфекция йогуның өч кенә юлы бар:

1. **Женси юл** – саклану чараларыннан (ягъни, презервативтан) башка ораль, вагиналь һәм аналь секс.
2. **Парентераль юл** – зарарланган кан аша. Кеше организмына ВИЧ белән зарарланган кан эләккәндә (гадәттә, наркотиклар кадаганда) стериль булмаган инструментлар куллану нәтиҗәсендә була.
3. **Вертикаль юл** – ВИЧның анадан балага күчүе. Уңай ВИЧлы ана үз баласына йөкле вакытта, тудырганда яисә аңа күкрәк сөте имезгәндә вирус йоктырырга мөмкин.

Көнкүреш юлы белән – үбешү, кул бирешү, бергә спорт белән шөгыльләнү, бер үк савыт-саба, кашык-чәнечкеләр, сөлгеләр куллану нәтиҗәсендә, һәм хәтта бөҗәкләр тешләгән очракта да, ВИЧ инфекциясе йокмый. Сәләгәй, яшь һәм сидектә вирусның концентрациясе зур түгел, шуңа күрә әлеге биологик сыеклык аша да зарарланып булмый.

## Кешенең ВИЧ белән зарарланган яки зарарланмаган булуын ничек ачыкларга?

Вирус йоктыргач кеше бернинди авыру билгеләре тоймый әле. Шуңа күрә, әгәр кайчан да булса наркотиклар куллангансың, саклану чараларыннан башка женси мөнәсәбәткә кергәнсең һәм шул ук вакытта үзеңнең һәм якыннарыңның сәламәт булуын телисең икән, сиңа ВИЧка тест үтәргә кирәк.

Анализ өчен венадан аз гына күләмдә кан алына. Анализ вируска каршы антитәнчекләр булу-булмауны ачыкларга ярдәм итә. Антитәнчекләр – кан плазмасының аксымнары. Алар организмга чит матдәләр – вируслар кергән очракта барлыкка килә.

ВИЧ антитәнчекләренә тестны СПИДка каршы көрәш һәм профилактика үзәкләрендә һәм башка медицина оешмаларында тапшырырга мөмкин. ВИЧка тест үтү синең күп вакытыңны алмас. Ул бушка, конфиденциаль (үзеңнән кала, нәтиҗәләрен бары тик СПИД үзәгендәге дәвалаучы табиб кына беләчәк) яки аноним (бу очракта исемне әйтү кирәкми) эшләнә.

## Серонегатив тәрәзә

ВИЧка тестны инфекция йоктыру куркынычы булган контакттан соң ук үтүнең мәгънәсе юк. ВИЧ йоктыру моментыннан алып антитәнчекләр барлыкка килү вакытына кадәр (алар булган очракта ВИЧ инфекция диагнозы куела да инде) беркүпме вакыт үтәргә тиеш (гадәттә, өч ай).

Бу вакыт аралыгында вена аша наркотиклар кулланганда һәм женси мөнәсәбәтләр вакытында инфекция йоктырмас өчен (әле йогып өлгермәгән булса) һәм, вирус синең организмыңа эләккән икән инде, димәк, башка кешеләргә йоктырмас өчен, аеруча нык саклану чаралары күрергә кирәк

## ВИЧ инфекцияләрне дәвалау

Дәваламаган очракта ВИЧ инфекцияле кешеләрнең сәламәтлеге иртәме-соңмы начарая башлый. Ел үткән саен кешенең иммун системасын вирус ныграк какшата бара, бу, үз чиратында, төрле авыруларның (аларны икенчел авырулар дип тә атыйлар, мәсәлән, пневмоцист пневмония, туберкулезның авыр формалары, гөмбә инфекцияләре (кандидоз), Капоши саркомасы, ракның кайбер төрләре һәм башка төрле авырулар) көчәеюнә китерә.

ВИЧ инфекцияне дәвалаганда куллана торган препаратларны антиретровирус (АРВ), ә ВИЧ инфекцияне шул препаратлар белән дәвалауны антиретровирус терапия (АРВТ) дип атыйлар. ВИЧ инфекцияне дәвалау өчен өч яки аннан да күбрәк АРВ препарат кулланалар. Мондый дәвалау югары активлыктагы антиретровирус терапия (ВААРТ) дип атала.

ВААРТ вирусны юк итми, ләкин аның кеше күзәнәкләренә үтеп керүен һәм күзәнәкләрдә үрчүен тоткарлый. Ул ВИЧ яшәү циклының өч төп стадиясенә тәэсир итә:

1. Вирус һәм кешенең иммун күзәнәкләре кушылмасын өчен киртә булып тора (CD4).
2. Вирусның күзәнәк эченә керүенә тоткарлык ясый.
3. Вирусның күзәнәк эчендә яңадан җитештерелүенә (репликация) киртә булып тора.

Бу вакытта организмдагы вируслар саны кими. Организмда сәламәт иммун күзәнәкләре күбрәк булган саен, ВИЧ азрак була, иммун системасы аны башка авырулардан яхшырак саклый, кеше үзен әйбәтрәк хис итә.

Вирус үрчүенең берничә этабына тәэсир итәр өчен өчтән дә ким булмаган АРВ препарат кулланырга кирәк. Алар ярдәмендә ВИЧ күзәнәкләре үрчүне тулысынча туктатырга мөмкин.

Шунысын да истә тоту кирәк: ВИЧ инфекцияне дәвалау инфекция булуын белгәннән соң түгел, ә дәвалаучы табиб тарафыннан күрсәтмә булган очракта гына башлана. Терапия башлангач даруларны даими рәвештә кабул итәргә кирәклеген дә онытырга ярамый, чөнки дәвалану вакытындагы тәнәфесләр иммун системасына һәм аның киләчәктә дәвалау процессына тәэсиренә негатив йогынты ясарга мөмкин.

Бала табарга җыенган уңай ВИЧлы хатын-кызларның вакытында табибка мөрәҗәгать итүе аеруча мөһим. Әгәр дә син үзең өчен махсус билгеләнгән медицина препаратларын регуляр рәвештә кабул итәсең икән, вирусның балага йогу куркынычы 2% һәм аннан да кимрәк була!

Россиядә ВААРТ препаратларын уңай ВИЧлы кешеләрнең күпчелеге, шул ук вакытта, наркотик кабул итүчеләр (яисә кайчан да булса кабул иткәннәр) дә куллана.

Иң мөһиме, ВИЧ инфекция белән СПИД үзәгендә теркәлгән очракта, үзеңнең сәламәтлегеңне яхшырта һәм гомереңне озынайта торган дәвалауны син бушка ала алачаксың.

